ГЛАВА
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода,
422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский Бистәсе авылы,
422591

Тел.: (84379) 30-1-48, факс (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                    КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс (84379) 30-1-48.

03.10.2023    с. Введенская Слобода    №2

«Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Введенский Бистәсе авылында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 14 октябренә Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Введенский Бистәсе авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Введенский Бистәсе авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллау белән килешәсезме:
- Введенский Бистәсе авылында су өчен өстәмә резервуарлар урнаштыру
«ӘЙЕ»                    «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Введенский Бистәсе, Үзәк урамы, 55 йорт адресы буенча 18:00 сәгатьтә Авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.
4. Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы                    Д.В. Морозов